**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422723 Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Алан-Бексер, ул.Центральная, д.19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур.,19 йорт

Тел./факс: +7(84365) 63-951, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**27 декабрь 2023 г.** **№ 93**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендә № 194 кабул ителгән “Җир салымы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 18.11.2019 № 194 карарына (Советның 19.05.2020 № 217, 16.11.2022 № 64, 29.11.2022, № 66, 01.11.2023 № 85 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның 1 нче пунктчасы 3 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-торак фонды һәм (яисә) торак - коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (күчемсез милек объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган җир участогы өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (сатып алынган (бирелгән) җир участокларыннан тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен); ».

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендәге 194 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында "2023 елның 1 ноябрендәге 85 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсенә ярашлы рәвештә законлы көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина